# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш торак пунктында үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

29 ноябрь 2021 ел

№2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 13 сәгать 00 минутта 2021 елның ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: 2022 елда Яшел Үзән муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;
2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

«ӘЙЕ» « КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **27** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **15** кеше катнашты, бу **55,56%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **15** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. 2022 елда үзара салым акчаларын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә Кызыл Кармыш авылында даими яшәүче һәр балигъ булган, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2000,00 сум күләмендә кертергә.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

3.1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

3.2. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;

4. Әлеге карарны Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru интернет

челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче И.М.Фатхуллин